РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 17 августы** **Чистай шәһәре** **№ 16/4**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 27 февралендәге 43/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына бюджет процессын камилләштерүгә бәйле рәвештә үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 07 маендагы 104-ФЗ номерлы Федераль законның 64 статьясындагы 64 пункты, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының «Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 27 февралендәге 43/4 номерлы карары белән (Чистай муниципаль районы Советының 2015 елның 11 мартындагы 44/4 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 38/3 номерлы, 2019 елның 27 декабрендәге 51/2 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1.4 пунктында «максатчан» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Палатаны Палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче һәм аның эшен оештыручы җитәкче җитәкли.

Палата җитәкчесе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлардан вазыйфага билгеләнә.

Кандидатларның Палата җитәкчесе вазыйфасын биләүгә квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла.

Палата җитәкчесе җирле үзидарә органының вазыйфаи заты булып тора.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (https:// pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (https://chistopol.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов